# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда үзара салым кертү турында
Иске Рәҗәп авыл җирлегенең Иске Рәҗәп торак пунктында
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

2023 елның 24 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлегенең Иске Рәҗәп торак пунктында гражданнар җыены

Карар:

1.2024 елда үзара салымны Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешедән, 400 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Иске-Рәҗәп торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (җәйге вакытта территорияне кисү һәм Иске-Рәҗәп торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, МТЗ тракторы һәм триммерлар өчен резина һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

- агачларны, куакларны кисү һәм утильләштерү, Иске-Рәҗәп торак пункты территориясендә гербицидлар сибү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Иске-Рәҗәп торак пунктында яшәүчеләрне радиоэлемтә хезмәтләре белән тәэмин итү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Иске-Рәҗәп торак пунктында " зур " плотинасын ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт хезмәтләре өчен түләү);

-Иске-Рәҗәп торак пунктында су күтәрү манараларын һәм скважиналарын ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Иске-Рәҗәп торак пунктында ритуаль хезмәтләр өчен материаллар сатып алу (такталар сатып алу);

- янгын сүндерү машиналарын ремонтлау (янгын сүндерү җиһазлары, ягулык-майлау материаллары һәм янгын сүндерү машиналары өчен запас частьләр сатып алу);

-һәйкәлне, мемориалны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-Иске-Рәҗәп торак пунктын төзекләндерү (килешү буенча эш өчен түләү )

3. Әлеге карарны Иске Рәҗәп авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару (http:// spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Спас Муниципаль районы
Иске Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.А.Нугаев